ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2020 г. Заинск № 145

**"Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак биналарны алмаштыруга ризалык алу өчен муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында"**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексы, "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 2018 елның 06 мартындагы 360 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. "Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак биналарны алмаштыруга ризалык алу өчен муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. 2018 елның 07 декабрендәге 1802 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән «Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 14 апрелендәге 691 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 07 декабрендәге 1802 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән «Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 18 июлендәге 1191 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында: http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

5. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасары М.И. Захаровага әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**